ГЛАВА ВАХИТОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Центральная, д.28, д. им. М. Вахитова, 422575

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ВАХИТОВ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Үзәк ур., 28 иче йорт, М. Вахитов исем авылы, 422575

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48

---

л.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 3(

д. им. М. Вахитова

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлегенең Ташевка авылында

07 октябрь 2023 № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә. Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 30 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 17 кеше. Кворум бар.

КАРАР ИТТЕ:

1. Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлегенең Ташевка авылында гражданнар җыенын узган дип танырга.

2. «Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге Ташевка авылында теркәлгән һәр балигъ булган кешедән Югары Ослан муниципаль районының Ташевка авылында, ташламалылар категориясеннән тыш, сез 2024 елда 1200 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрү белән килешәсезме? - Ташевка авылы җирлегендә зиратны төзекләндерү, дигән сорау буенча кабул ителгән карарны танырга.

3. Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлегенең Ташевка авылы гражданнары җыенының нәтиҗәләрен Вахитов авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Каримов Ф. Р.